# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** 10.12.2019 ел

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Үрәзмәт авыл жирлеге составына керүче
Сикия торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Сикия торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Сикия торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. 1 һәм 2 төркем инвалидларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
-Сикия авылы урамнарын җәйге һәм кышкы карап тоту;
- Мәктәп урамы 100 метр Сикия авылы адресы буенча койма урнаштыру;
-Сикия авылында яктырткычлар сатып алу һәм урам утларына хезмәт күрсәтү;
-Сикия авылында үлән чабу һәм куаклар кисү;
- Сикия авылында агач утырту;
- Сикия авылы зиратын карап тоту.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Үрәзмәт авылы, Мәктәп урамы, 46а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы Ә.Г. Закирянов